КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 июнь г.Казань № 501

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка объектларны өлешләп төзү, шулай ук күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»

2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлеге өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибендә:

3 пунктта «өлешләп төзү өчен гражданнар» сүзләрен «төзү (булдыру) өченөлешләп төзүдә катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга»;

5 пунктның икенче абзацында «план яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 – $6^{10}$ пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин